КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 11 июль г.Казань № 562

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 315 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгын үзгәртеп кору турында» 2018 ел, 22 июнь, ПУ-454 нче Указын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 315 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 663 нче; 2006 ел, 2 май, 216 нчы; 2008 ел, 27 июнь, 449 нчы; 2009 ел, 13 июль, 491 нче; 2010 ел, 11 июнь, 465 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1035 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 29 август, 724 нче; 2011 ел, 29 август, 726 нчы; 2012 ел, 8 сентябрь, 761 нче; 2013 ел, 19 март, 190 нчы; 2014 ел, 1 февраль, 54 нче; 2014 ел, 1 февраль, 150 нче; 2014 ел, 16 май, 325 нче; 2014 ел, 26 декабрь, 1042 нче; 2015 ел, 30 июнь, 472 нче; 2016 ел, 13 май, 301 нче; 2016 ел, 22 октябрь, 769 нчы; 2016 ел, 30 ноябрь, 880 нче; 2017 ел, 22 май, 295 нче; 2018 ел, 9 апрель, 223 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы мәсьәләләре»;

1 нче пунктта «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы» дигән сүзләргә алыштырырга;

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы хезмәткәрләренең иң чик

санын вазыйфаи эш хаклары буенча 1 133,5 мең сум күләмендәге айлык хезмәт өчен түләү фонды белән 51 берәмлек дип билгеләргә.»;

3 нче пунктта «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Спорт министрлыгына» сүзләренә алыштырырга;

4 – 8 нче пунктлар үз көчен югалткан дип санарга;

10 нчы пунктта «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Спорт министрлыгына» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы турындагы нигезләмәне бу карарга теркәлгән кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы структурасын бу карарга теркәлгән кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2005 ел, 6 июль, 315 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 11 июль, 562 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык) физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт идарәсен һәм эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы булып тора.

1.2. Министрлык теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге оешмалар белән бу Нигезләмәгә теркәлгән кушымтада күрсәтелгән эшчәнлек төрләре буенча үз компетенциясе чикләрендә үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра.

1.3. Министрлык үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Татарстан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм боерыкларына, шулай ук бу Нигезләмәгә таяна.

1.4. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә эшчәнлекне федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлектә гамәлгә ашыра.

1.5. Министрлык юридик зат була, аның мөстәкыйль балансы, банк учреждениеләрендә билгеләнгән тәртиптә ачыла торган хисап исәпләре һәм башка исәпләре, Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә үз исеме язылган һәм Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәтләнгән мөһере, үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка мөһерләре, штамплары һәм бланклары бар.

1.6. Министрлыкның урнашу урыны (юридик адресы): 420107, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Петербург урамы, 12 нче йорт.

## 2. Министрлыкның бурычлары

Министрлыкның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

массакүләм физик культураны үстерү һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру максатларында, республика халкының физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүе өчен һәркем файдалана ала торган шартлар булдыруга ярдәм итү;

югары казанышлар спортын үстерү.

## 3. Министрлыкның функцияләре

3.1. Министрлык түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыру өчен җавап бирә:

физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә итү (04.04 <*>)[1], шул исәптән:

физик культура һәм спорт учреждениеләре инфраструктурасын үстерү өлкәсендә җайга салу (04.04.01 <*>);

физкультура-савыктыру һәм массакүләм спорт чаралары (шул исәптән республика һәм муниципальара чаралар), бөтенроссия һәм халыкара спорт ярышларын һәм өйрәнү-күнегү җыеннарын оештыру белән идарә итү (04.04.02 <*>);

Татарстан Республикасының спорт җыелма командаларын һәм аларның ярышларда чыгыш ясауларын әзерләүне билгеләнгән тәртиптә тәэмин итү (04.04.03 <*>).

3.2. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән үзара хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалар эшләү (01.01 <*>);

инвестиция эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу (01.10 <*>);

инновация эшчәнлеген үстерү белән идарә итү (01.11 <*>);

Татарстан Республикасының ведомстволарга караган дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.2 <*>);

Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

бюджет процессы (Татарстан Республикасы һәм бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджеты) белән идарә итү (01.02.1 <*>);

бюджетара мөнәсәбәтләрне җайга салу (01.02.3 <*>);

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән – Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез мөлкәттән (биналар, корылмалар), транспорттан, җиһазлардан, мәдәни мирас объектларыннан файдалану белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07.01 <*>);

Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән – энергияне һәм ресурсларны саклау белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.14 <*>);

---

1 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторы

Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы милкендәге мәдәни мирас объектларын саклау, файдалану һәм популярлаштыру (04.03.03 <*>);

республика әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларын дәүләт тарафыннан саклау (04.03.04 <*>);

федераль милектәге мәдәни мирас объектларын саклауны, файдалануны һәм популярлаштыруны һәм федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын дәүләт тарафыннан саклауны билгеләнгән тәртиптә тәэмин итү (04.03.05 <*>);

федераль милектәге мәдәни мирас объектларын саклау, файдалану һәм популярлаштыру белән федераль бюджет субвенцияләре хисабына идарә итү (04.04.06 <*>);

федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын бирелгән вәкаләтләр чикләрендә федераль бюджет субвенцияләре хисабына дәүләт тарафыннан саклау (04.03.07 <*>);

Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы карамагындагы оешмаларда балаларга өстәмә белем бирү эшчәнлеге белән идарә итү (04.05.01.4 <*>);

урта һөнәри белем бирү белән (федераль белем бирү оешмаларында алына торган белемнән тыш) билгеләнгән тәртиптә идарә итү (04.05.06 <*>);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Балигъ булмаганнар эшләре буенча республика комиссиясе белән – балигъ булмаганнарның караучысыз калуын һәм хокук бозуларын профилактикалау белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.06.03 <*>);

Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

хезмәт өчен түләүне, хезмәт мөнәсәбәтләрен, турыдан-туры хезмәткә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга салу (01.13.01 <*>);

хезмәтне саклау белән идарә итү (01.13.02 <*>);

Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын әзерләүне тәэмин итү (01.05.01.01 <*>);

территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләүне тәэмин итү (01.05.02 <*>);

шәһәр төзелешен проектлауның төбәк нормативларын әзерләүне тәэмин итү (01.05.03 <*>);

Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән – Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларын үстерү белән идарә итү (дәүләт мәгълүмат ресурсларын булдыру белән идарә итүдән тыш) функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.02 <*>);

Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән – Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.01.03 <*>);

Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив документлар әзерләү эшчәнлеген яраштыру (шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килү-килмәвен тикшерүдә тоту) (02.04.01 <*>);

республика башкарма хакимият органнарының норматив хокук актларын дәүләт теркәвенә алу (02.04.03 <*>);

Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы белән – дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыру өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.07 <*>);

Татарстан Республикасының Архив эшләре буенча дәүләт комитеты белән – архив эшләре белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.03 <*>);

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты белән – социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.01.1<*>).

3.3. Министрлык бу Нигезләмәнең 3.1 нче, 3.2 нче пунктлары нигезендә түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

физик культура һәм спорт үсешенә комплекслы анализ ясауны һәм аны фаразлауны оештыру;

физик культураны һәм спортны үстерү өлешендә дәүләт социаль-икътисадый сәясәтен эшләүдә һәм тормышка ашыруда катнашу, шул исәптән физик культураны һәм спортны үстерү стратегиясен һәм концепциясен эшләү;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары белән берлектә, физик культура һәм спорт өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү һәм тормышка ашыру;

спорт инфраструктурасын үстерүдә катнашу, физкультура-спорт оешмалары эшчәнлеген камилләштерү;

дәүләт учреждениеләренең матди-техник базасын үстерүне тәэмин итү;

дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкаруны, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуларны формалаштыру;

дәүләт учреждениеләре биналарын һәм корылмаларын капиталь төзүгә, реконструкцияләүгә һәм ремонтлауга заказ булдыру, «Физкультура һәм спорт» тармагы буенча республика инвестиция программаларын формалаштыруда катнашу;

физкультура-савыктыру һәм массакүләм спорт чараларының календарь планнарын эшләү һәм үтәүне оештыру;

планлаштырыла торган елга бюджет турындагы Татарстан Республикасы законы проектын эшләүдә катнашу;

физик культура һәм спорт өлкәсендәге чараларны тормышка ашыруга бюджет чыганакларыннан алынган финанс чаралары белән эш итү;

Министрлыкның, шулай ук аның карамагындагы учреждениеләрнең бюджет эшчәнлеге буенча бухгалтерлык һәм статистика хисаплылыгын билгеләнгән вакытларда тапшыру;

Министрлык эшчәнлеген хокукый тәэмин итү, физик культура һәм спорт өлкәсендәге Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү һәм аларны билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертү, аларның тормышка ашырылуын тикшерүдә тотуны тәэмин итү;

дәүләт спорт корылмаларының нәтиҗәле һәм рациональ файдаланылуын тикшерүдә тотуны оештыру;

гомуми белем бирү дәүләт стандартын тормышка ашыру өлешендә Министрлыкның ведомство буйсынуындагы гомуми белем бирү учреждениеләрендә («физкультура һәм спорт» эшчәнлек төрләре буенча балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре өлешендә) гражданнарның һәркем алырлык һәм түләүсез гомуми белем алу хокукларына дәүләт гарантияләрен тәэмин итү буенча җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын дәүләт тикшерүендә тоту;

физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт социаль нормаларын, нормативларын һәм стандартларын эшләүдә катнашу һәм аларның үтәлешен тикшерүдә тотуны оештыру;

физик культура һәм спорт өлкәсендә статистика исәбен һәм хисаплылыкны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү;

физик культура һәм спорт өлкәсендәге эшчәнлекне фәнни, аналитик, методик тәэмин итү системасын оештыру һәм камилләштерү;

физик культура һәм спорт өлкәсендә махсуслашкан кадрларга аттестация үткәрү тәртибен билгеләү, аларны әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрүне тәэмин итү;

физик культура һәм спорт мәсьәләләре буенча һәр граждан өчен ачык булган мәгълүмат ресурсларын булдыруда булышлык күрсәтү;

физик культура һәм спорт өлкәсендә мәгълүмат һәм нәшрият эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

Россия һәм халыкара спорт оешмаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты кушуы буенча аның мәнфәгатьләрен яклау;

Министрлык ведомствосына караган мәсьәләләр буенча гражданнарның тәкъдимнәрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен законнарда билгеләнгән вакытларда карап тикшерү;

физик культура һәм спорт өлкәсендә халыкара һәм төбәкара хезмәттәшлекне оештыру һәм үстерү;

спорт иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегенә һәм аларның инициативаларына булышлык күрсәтү, Министрлык бурычларын тормышка ашырганда үзара хезмәттәшлек оештыру;

җирле бюджетларның муниципаль үсеш фондыннан, социаль чыгымнарны финанслашуның төбәк фондыннан алынган субсидияләрдән нәтиҗәле файдалануын бәяли торган индикаторлар турында җирле үзидарә органнары белән килешүләр әзерләүне, төзүне тәэмин итү;

рәсми республика һәм муниципальара физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрү;

Министрлыкның, эшчәнлекләре Министрлык эшчәнлегенә бәйле булган яки аның карамагы өлкәсендәге оешмаларның мобилизация әзерлеген һәм мобилизациясен оештыру һәм тәэмин итү, шулай ук бу чараларны методик яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыру;

Министрлык ведомствосы буйсынуындагы учреждениеләр булып торучы заказчылар өчен заказлар урнаштыру (Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен үзәкләштереп сатып алына торган товарларның, заказ бирелә торган эшләрнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең детальләштерелгән исемлеге буенча заказ урнаштырудан тыш) функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булып тора;

дәүләт ихтыяҗлары һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру өлкәсендәге федераль законнар нигезендә электрон мәйданчык операторына вәкаләтле орган исеменнән эш итү хокукы булган затның электрон санлы имзасы куелган, заказчы тарафыннан имзаланган контракт күчермәсен җибәрә;

үз компетенциясе нигезендә федераль башкарма хакимият органнары, аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, Россиянең һәм чит илләрнең башка органнары һәм оешмалары белән төзелгән шартнамәләрнең, килешүләрнең һәм ачык-хокукый характердагы башка актларның реестрын алып бара;

ел саен, 1 февральгә, Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру буенча махсус дәүләт органына коррупциягә каршы сәясәт чараларын тормышка ашыру турында хисап кертә;

ведомство буйсынуындагы Татарстан Республикасы дәүләт казна, бюджет һәм автоном учреждениеләрен (алга таба – учреждениеләр) гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара, шул исәптән:

учреждениеләр оештыру, үзгәртеп оештыру, типларын үзгәртү, бетерү турында карарлар проектларын әзерли, аларның уставларын раслый һәм аларга үзгәрешләр кертә;

учреждениеләргә эшчәнлекнең учреждение уставы белән күздә тотылган төп төрләре нигезендә юридик һәм физик затларга дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыра һәм раслый;

учреждениеләрне гамәгә куючының башка функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара;

учреждениеләр күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартлары проектларын эшли;

учреждениеләр фактта күрсәтә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне ел саен бәяли;

учреждениеләр эшчәнлегенең учреждениеләр эшчәнлеген бәяләү буенча билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәүне бәяли;

Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган Россия Федерациясендә хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыру методикасы нигезендә үз

компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасында хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыра;

урта һөнәри һәм югары белем бирү һөнәрләре һәм белгечлекләре буенча квалификацияле белгечләрне тармакта әзерләү ихтыяҗы фаразын формалаштыруны оештыра;

Татарстан Республикасының фәнни-белем бирү кластерларында белгечләр әзерләүгә, яңадан әзерләүгә һәм аларның квалификациясен күтәрүгә дәүләт заказына тәкъдимнәр формалаштыра;

тармакны кадрлар белән тәэмин итү торышын өйрәнә;

үз компетенциясе чикләрендә экстремизм эшчәнлегенә һәм террорчылыкка каршы торуда катнаша, Министрлыкка беркетелгән объектларның террорчылыктан сакланган булуын тәэмин итә;

физик культура һәм спорт өлкәсендәге оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләүне оештыра;

үз компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү өчен Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә гражданнарга телдән һәм язмача хокукый консультация бирү рәвешендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтә;

федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокук актлары белән билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә социаль ярдәмгә һәм социаль яклауга мохтаҗ гражданнарга гаризалар, шикаятьләр, үтенечнамәләр һәм хокукый характердагы башка документлар язу рәвешендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтә һәм судларда, дәүләт органнарында һәм муниципаль органнарда, оешмаларда граждан мәнфәгатьләрен яклый.

3.3.1. Физик культура һәм спорт өлкәсендә:

халыкның физик үсеше буенча мониторинг үткәрү;

массакүләм спорт үсешен тәэмин итүдә булышлык күрсәтү һәм аңа республика халкының барлык категорияләрен тартуны арттыру;

балалар, үсмерләр һәм студентлар спортын үстерүдә булышлык күрсәтү;

балалар-үсмерләр спорт мәктәпләренең тренер-укытучыларына, җитәкчеләренә һәм инструктор-методистларына квалификация категорияләре бирү;

балалар-үсмерләр спорт мәктәпләре укучыларына Бердәм Бөтенроссия спорт квалификациясе нигезендә спорт разрядлары һәм исемнәре бирү;

физик культураны һәм спортны, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау эшен үткәрү;

республика спорт федерацияләренә дәүләт аккредитациясен гамәлгә ашыру;

коммерциягә карамаган оешмаларга «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ХОӘ) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынаулар нормативларын (тестларын) үтәүне бәяләү хокукын бирү;

спортның милли төрләрен үстерүне оештыру, шул исәптән Татарстан Республикасында үстерелә торган спортның милли төрләре буенча спорт чараларын үткәрү тәртибен билгеләү;

Татарстан Республикасында инвалидларның һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларның физик культурасын һәм спортын,

адаптацияләнгән физик культураны һәм адаптацияләнгән спортны үстерү чараларын тормышка ашыру;

республика спорт әзерлеге үзәкләре эшчәнлеген тәэмин итү.

3.3.2. Югары казанышлар спорты өлкәсендә:

спорт резервын һәм югары класслы спортчылар әзерләү системасын тәэмин итү һәм тормышка ашыру;

югары казанышлар спорты төрләрен үстерүгә, Россия җыелма командалары әгъзалары булган Татарстан Республикасы спортчыларына аларның югары спорт нәтиҗәләренә ирешүләре максатыннан чыгып булышлык күрсәтү;

Татарстан Республикасының җыелма спорт командаларын әзерләүне тәэмин итү;

Татарстан Республикасының спорт җыелма командалары спортчыларын медицина-биология ягыннан тәэмин итүне оештыру;

сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан әзерләнгән Татарстан Республикасының спорт җыелма командалары спортчыларын медицина-биология ягыннан тәэмин итүне оештыру тәртибен килештерү.

3.4. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә түбәндәге хокукларга ия:

физик культура һәм спорт дәүләт учреждениеләре системасындагы дәүләт мөлкәте белән эш итү мәсьәләләрен дәүләт мөлкәте белән идарә итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы белән билгеләнгән тәртиптә килештерергә;

дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген финанслауны билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә;

дәүләт учреждениеләрен, аларның филиалларын һәм вәкиллекләрен билгеләнгән тәртиптә оештыру, үзгәртеп оештыру һәм бетерү турында тәкъдимнәр кертергә;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан Министрлык компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат соратып алырга;

үз вәкаләтләре чикләрендә чит федератив дәүләтләр субъектлары, чит дәүләтләрнең административ-территориаль берәмлекләре белән халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук бу максатлар өчен махсус төзелгән органнар кысаларында халыкара оешмалар эшчәнлегендә катнашырга;

ведомство бүләкләрен раслау, алар белән физик культура һәм спорт дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләрен бүләкләү турында карарлар кабул итәргә һәм бүләкләүнең башка төрләрен кулланырга;

Министрлык ведомствосы буйсынуындагы учреждениеләр булып торучы заказчылар өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар буенча (Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен үзәкләштереп сатып алына торган товарларның, заказ бирелә торган эшләрнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең детальләштерелгән исемлеге буенча сатып алулардан тыш) функцияләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булырга;

дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендәге федераль законнар нигезендә электрон мәйданчык операторына вәкаләтле орган исеменнән эш итәргә хокуклы затның электрон санлы имзасы куелган, заказчы имзалаган контракт күчермәсен җибәрергә;

Министрлык ведомствосы буйсынуындагы учреждениеләр булып торучы заказчылар исеменнән электрон аукцион йомгаклары буенча төзелә торган контракт проектына квалификацияле булмаган көчәйтелгән электрон имза куярга;

заказчылар өчен «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 ел, 5 апрель, ФЗ-44 нче Федераль закон белән күздә тотылган документларны һәм мәгълүматны бердәм мәгълүмат системасында урнаштырырга.

## 4. Министрлык эшчәнлеген оештыру

4.1. Министрлыкка Татарстан Республикасы Конституциясе билгеләгән тәртиптә вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган министр җитәкчелек итә.

4.2. Министр:

аның тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган урынбасарлары була;

Министрлык эшчәнлегенә бер үзе идарә итә торган гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыра һәм Министрлыкка йөкләнгән функцияләрне үтәү өчен шәхсән җавап бирә;

хезмәткәрләрнең билгеләнгән саны, хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә Министрлык аппаратын тоту өчен чыгымнар сметасын, штат расписаниесен раслый;

үз компетенциясе чикләрендә билгеләнгән тәртиптә боерыклар чыгара, кагыйдәләр, тәгълимнамәләр, нигезләмәләр раслый (кирәк булган очракларда – Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары белән берлектә), аларны үтәү турында күрсәтмәләр бирә һәм тикшерүдә тотуны оештыра;

Министрлык аппараты һәм аның структур бүлекчәләре хезмәткәрләренең вазыйфаи тәгълимнамәләрен раслый;

Министрлык аппараты хезмәткәрләрен билгеләнгән тәртиптә вазыйфаларына билгеләп куя һәм вазыйфаларыннан азат итә;

үз компетенциясе чикләрендә Россия һәм чит ил оешмалары белән физик культураны һәм спортны үстерү, федераль һәм халыкара программаларда катнашу мәсьәләләре буенча шартнамәләр һәм килешүләр төзи;

үзләрен аеруча яшы яктан күрсәткән хезмәткәрләрне мактаулы исемнәр бирүгә, дәүләт бүләкләре белән бүләкләүгә билгеләнгән тәртиптә тәкъдим итә, матди һәм мораль яктан бүләкләү чараларын күрә, хезмәткәрләрне тармакның мактаулы билгеләре белән бүләкли;

боерык белән министр урынбасарлары, структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре исемлеген раслый;

боерык белән Министрлыкка беркетелгән процессларны (ярдәмче процессларны) үтәү стандартларын раслый һәм аларның үтәлешен тәэмин итә;

боерык белән нәтиҗәлелекнең төп күрсәткечләренә ирешү нәтиҗәләре нигезендә министр урынбасарлары, структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм Министрлык хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турындагы нигезләмәне, шулай ук, эшчәнлек нәтиҗәлелегенең ирешелгән төп күрсәткечләреннән чыгып, стимуллаштыру түләүләре күләмнәрен исәпләп чыгару тәртибен билгеләү турындагы нигезләмәне раслый;

Министрлык өчен билгеләнгән нәтиҗәлелекнең төп күрсәткечләре һәм хезмәт законнары нигезендә ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләре белән контрактлар (хезмәт шартнамәләренә өстәмә килешүләр) төзи;

Россия допингка каршы оешмасы, физик культура һәм спорт өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы, Россия Федерациясенең спорт җыелма командалары спортчыларын медицина-биология ягыннан тәэмин итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы белән хезмәттәшлек итеп, спортта допингны кисәтү һәм аңа каршы көрәш эшен оештыру өчен җаваплы вазыйфаи затны билгеләп куя.

4.3. Министрлыкта физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт идарәсе функцияләрен гамәлгә ашыруга бәйле булган иң мөһим мәсьәләләр буенча карарлар эшләү төп бурычы булып торган коллегия төзелә.

Коллегия составына министр, министрның вазыйфа буенча урынбасарлары, структур бүлекчәләр җитәкчеләре, шулай ук физик культура һәм спорт өлкәсендә махсус вәкаләтле органнар, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары җитәкчеләре, оешмалар һәм предприятиеләр җитәкчеләре, республика галимнәре керә.

Коллегиянең составы һәм әгъзалар саны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

Министр коллегиянең рәисе була.

4.4. Министрлыкта яраштыру советлары, ведомствоара комиссияләр төзелергә мөмкин.

Күрсәтелгән советларның составлары һәм алар турындагы нигезләмәләр министр тарафыннан раслана.

Татарстан Республикасының
Спорт министрлыгы турындагы
нигезләмәгә кушымта

Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы
оешмалар, предприятиеләр, учреждениеләр белән
үзара хезмәттәшлек итә торган икътисадый эшчәнлек төрләре
исемлеге

| ОКВЭД <*> | Икътисадый эшчәнлек төрләре исеме |
|---|---|
| 84.11.21 | Россия Федерациясе субъектларының (республикаларның, крайларның, өлкәләрнең) дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеге (Россия Федерациясе Президенты каршындагы Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары вәкиллекләреннән, суд хакимиятеннән һ.б. тыш) |
| 75.11.8 | Дәүләт милкендәге мөлкәт белән идарә итү |
| 75.13 | Икътисадый эшчәнлекне җайга салу һәм аны нәтиҗәле алып баруга булышлык күрсәтү, төбәк, илкүләм һәм яшьләр сәясәте өлкәсендәге эшчәнлек |
| 75.14 | Дәүләт идарәсе өлкәсендәге ярдәмче эшчәнлек |
| 80.10.3 | Балаларга өстәмә белем бирү |
| 80.22.21 | Урта һөнәр белеме бирүче мәгариф учреждениеләрендә уку |
| 92.2 | Радиотапшырулар һәм телевидение өлкәсендәге эшчәнлек |
| 92.6 | Спорт өлкәсендәге эшчәнлек |
| 92.61 | Спорт объектлары эшчәнлеге |
| 92.62 | Спорт өлкәсендәге башка эшчәнлек |
| 93.04 | Физкультура-савыктыру эшчәнлеге |

_______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2005 ел, 6 июль, 315 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 11 июль, 562 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасының Спорт министерлыгы
структурасы

